РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«30» сентябрь 2022 ел Олы Кайбыч ав. № 146

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2011 елның 17 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен контрольләү турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2011 елның 17 мартындагы 45 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе турында нигезләмәгә 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, хисап чорына цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алуга кагылышлы алыш-бирешнең гомуми суммасы алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр.»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Айзатуллова Р.Г.га йөкләргә.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин